**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге составына керүче Комсомол поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

19 ноябрь, 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 19 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Комсомол авыл җирлегенең Комсомол поселогы территориясендә 2023 елда балигъ булган, Комсомол авыл җирлегенең Комсомол поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 600 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

– зиратны төзекләндерү;
– чишмәне төзекләндерү;
– бистә эчендәге юлларны ремонтлау һәм реконструкцияләү;
– массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү

«Комсомол авыл җирлегенең Комсомолец поселогы территориясендә 2023 елда РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, аларның гаилә әгъзаларының үзара салым түләүләреннән азат итәргә ризамы?

“ӘЙЕ” “ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **<u>692</u>** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **<u>347</u>** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәлә 346 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **<u>1</u>** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Комсомол поселогында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. « Комсомол авыл җирлегенең Комсомол поселогы территориясендә 2023 елда балигъ булган, Комсомолец авыл җирлегенең Комсомолец поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 600 сум күләмендә

бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне Сез ризамы:

– зиратны төзекләндерү;

– чишмәне төзекләндерү;

– бистә эчендәге юлларны ремонтлау һәм реконструкцияләү;

– массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү

3. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Комсомол авыл җирлеге территориясендә теркәлгән аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнос түләүдән азат итәргә

4. Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Комсомол авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Тукай муниципаль районы Комсомол авыл җирлеге Комсомол авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комсомол авыл җирлеге Башлыгы О.В.Сурова